ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСАЛИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление                                                                                    Карар

№ 36                                                                                    14 декабрь 2022 ел.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Үсәли авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2017елның 22 декабрендәге
№12 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплар турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгы куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федерал закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга карш режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерл Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режи кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 188 номерлы карарлары нигезендә, Үсәли авыл җирлеге территориясендә янгын каршы тотрыклылыкны арттыру максатларында Мамадыш муниципаль район Үсәли авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Үсәли авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә чүп, үләннәр, яфрак һәм башк калдыкларны, материалларны яки әйберләрне яндыру урыннарын һәм ысуллары билгеләү турында» Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Үсәл авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017елның 22 декабрендәге №12 карарын (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Караның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Үсәли авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларының гомуми файдаланудагы җирләренд шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан шәхси йортла территорияләрендә ризык әзерләү өчен махсус бүленгән һәм моның өче җиһазландырылган урыннардан тыш ачык уттан файдалану, шулай ук чүп-чарны үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яки эшләнмәләрн яндыру тыела.»

1.2. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яндыру урыны итеп түбәндәге территорияләрне билгеләргә:

| N п/п | Торак пункт исеме | Чүп яндыру урыны | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Үсәли авылы | Торак пункттан көнчыгыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 2. | Югары Кыерлы авылы | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 3. | Владимир авылы | Торак пунктның көнбатыш өлешендә | Башкарма комитет |
| 4. | Бөрсет Сукачы авылы | Торак пункттан көньяк-көнбатышка таба | Башкарма комитет |
| 5. | Дружба поселогы | Торак пункттан көньяк-көнчыгышка таба | Башкарма комитет |
| 6. | Күк-Чишмә авылы | Торак пункттан көньяк-көнбатышка таба | Башкарма комитет |

1.3. Түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:
«Чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны яис эшләнмәләрне яндыру ысулы - ачык учак дип билгеләргә.»

1.4. Түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:
«Чүп –чарны яндыруны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенд Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендә 1479 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә башкарырга.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында , Мамадыш муниципал районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкк җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Үсәли
авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе

А.И.Зиатдинов